**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"15" ноябрь 2025 ел. № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, тавыш бирү хокукына ия булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү. (Чишмәле Сап авылында чишмә ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2) Коеларны төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Чишмәле Сап авылында коены ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2024 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын, түбәндәге җирле сорауларны чишүгә юнәлтергә:

3) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.
(Чишмәле Сап авылында һәйкәл территориясен яшелләндерү (яшел утыртмалар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); (Чишмәле Сап авылы балалар мәйданчыгын төзкләндерү (җиһазлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); Чишмәле Сап авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет Новошашинского сельского поселения Яңа Шашы авыл җирлеге Советы

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.